ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 633-208/кс-2022

«Нурлат торак-коммуналь хуҗалыгы күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2023 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра торган «Нурлат торак-коммуналь хуҗалыгы күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Нурлат ТКХ КҖП» МУП) тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга Федераль тарифлар хезмәтенең 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрнең 114.1 пункты нигезендә билгеләнә торган формула рәвешендә билгеләргә:

$$Т_{закр}^{гвс} = Т_{хвс} + Т_{i}^{тэ} * Q^{т/э}$$

биредә: $Т_{хвс}$ – «Нурлат ТКХ КҖП» МУП акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 338-54/кс-2022 карары нигезендә билгеләнгән тариф;

$Т_{i}^{тэ}$ – җылылык энергиясенә (егәрлегенә) компонент яклар килешүе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую нигезләренең 5(5) пункты нигезендә билгеләнә торган тариф;

$Q^{т/э}$ – салкын суның бер кубик метрын җылыту өчен кирәкле, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының 2017 елның 26 октябрендәге 189/о номерлы боерыгы нигезендә билгеләнә торган җылылык энергиясе (егәрлек) күләме.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Нурлат ТКХ КҖП» МУП Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Нурлат торак-коммуналь хуҗалыгы күптармаклы җитештерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2022 елга тарифлар билгеләү хакында» 16.12.2021 № 662-186/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев